## «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы – 2026»

Балтачта «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы – 2026» Бөтенрәсәй һөнәри бәйгесенең зона этабы узды. Балтач гимназиясе базасында Теләче, Арча, Кукмара, Балтач, Әтнә, Биектау укытучылары үзара көч сынашты.

